КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 23 июнь г.Казань № 421

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын һәм Red Bull Air Race World Series үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында» 2017 ел, 28 март, 196 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын һәм Red Bull Air Race World Series үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында» 2017 ел, 28 март, 196 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Казансу елгасы участогында Ленин дамбасыннан алып Чуйков-Гаврилов урамнары чатына кадәр кечкенә суднолар, шулай ук җилкәнле, йөреп кайту, спорт өчен каралган суднолар, шул исәптән гидроцикллар, байдаркалар, ишкәкле көймәләр куллануны түбәндәге вакытларда тыярга:

2017 елның 22 июнендә 16.00 сәгатьтән 2017 елның 23 июнендә 02.00 сәгатькә кадәр;

2017 елның 24 июнендә 13.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр;

2017 елның 28 июнендә 16.00 сәгатьтән 2017 елның 29 июненнән 02.00 сәгатькә кадәр;

2017 елның 8 июлендә 08.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр;

2017 елның 17 июленнән 24 июленә кадәр көн саен 08.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин